Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

22 июль 2019 ел № 23

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча 2019 елның 25 мартындагы 2090 и номерлы комиссия бәяләмәсенә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалану рөхсәт ителгән төргә - «аерым торучы көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларына» рөхсәт бирү мәсьәләсе, җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт төрләре классификаторы буенча код 3.3 – Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль район, Әлмәт шәһәре, Монтажная урамы, 5Б адресы, 16:45:040102:3489 кадастр номерылы җир кишәрлегенә карата ьәмәгать тыңлауларын билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 2 августы 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә бер айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдаланугa рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 2 августына кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.М. Токарев